# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлеге Кызыл Төбәк торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

**24.11.2022 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 24.11.2022 елда үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре буенча халык җыены беркетмәсе төзелде, «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иркәнәш авыл җирлеге Кызыл Төбәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы,1 һәм 2 группа инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-Кызыл Төбәк торак пунктында зират территориясен киртәләүне ремонтлауны тәмамлау (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эшләрне урнаштыру, түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 83 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 51 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 51 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Кызыл Төбәк торак пунктында гражданнар җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танылды.

2. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иркәнәш авыл җирлеге Кызыл Төбәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы.1 һәм 2 группа инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм

алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-Кызыл Төбәк торак пунктында зират территориясен киртәләүне ремонтлауны тәмамлау (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эшләрне урнаштыру, түләү).

3. Җыенның нәтиҗәләрен Иркәнәш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://menzelinsk.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән ун көн эчендә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иркәнәш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Иркәнәш авыл җирлеге башлыгы ____________ Камалов И. З.
(имза)